**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» апрель 2019 ел № 114

«Актүбә элеватор комплексы, отпайка
ЛЭП 6 кВ фидер 24-07 (төп туклану) һәм
отпайка ЛЭП 6 кВ фидер 07-05 (резерв туклану)
«Тышкы челтәрләр» («Наружные сети») 6кВ
объекты өчен Азнакай муниципаль районы
Актүбә бистәсе, Микулино авыл җирлеге
территориясе чикләрендә планлаштыру һәм межалау
проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Азнакай муниципаль районында ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар бирәм:

1.«Актүбә элеватор комплексы, отпайкаЛЭП 6 кВ фидер 24-07 (төп туклану) һәм отпайка ЛЭП 6 кВ фидер 07-05 (резерв туклану)«Тышкы челтәрләр» («Наружные сети») 6кВ объекты өчен Азнакай муниципаль районы Актүбә бистәсе, Микулино авыл җирлегетерриториясе чикләрендә планлаштыру һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Ачык тыңлаулар үткәрү инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты — 2019 елның 15 апреленнән 2019 елның 16 маена кадәр 08.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр, тәнәфес 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны – Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 22 йорт;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2019 елның 16 маена кадәр - Азнакай шәһәре, М. Солтангалиев урамы, 24 йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр төшке ашка 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр тәнәфес) кертелә ала.

4. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетына:

- «Актүбә элеватор комплексы, отпайкаЛЭП 6 кВ фидер 24-07 (төп туклану) һәм отпайка ЛЭП 6 кВ фидер 07-05 (резерв туклану)«Тышкы челтәрләр» («Наружные сети») 6кВ объекты өчен Азнакай муниципаль районы Актүбә бистәсе, Микулино авыл

җирлегетерриториясе чикләрендә планлаштыру һәм межалау проекты буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар нигезендә билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Кушымта нигезендә Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру проекты һәм межалау проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын расларга.

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru..

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык М.З. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы карарына
кушымта
« ___ »________2019 ел №______

«Актүбә элеватор комплексы, отпайкаЛЭП 6 кВ фидер 24-07 (төп туклану) һәм отпайка ЛЭП 6 кВ фидер 07-05 (резерв туклану)«Тышкы челтәрләр» («Наружные сети») 6кВ объекты өчен Азнакай муниципаль районы Актүбә бистәсе, Микулино авыл җирлегетерриториясе чикләрендә планлаштыру һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча
эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Шәмсетдинов А.Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем секретаре:* | |
| Әюпова Р.Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Шәрәфетдинова С.Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов М. И. | Азнакай муниципаль районының Актүбә бистәсе Башкарма комитеты җитәкчесе(килешү буенча) |
| Такиулин И.А. | Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |